КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 ел, 8 июнь г.Казань № 436

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2021 ел, 16 февраль, 84 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2021 ел, 16 февраль, 84 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе җитәкчесенең хезмәте өчен түләү төркеме аның территориясендә Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе үз эшчәнлеген гамәлгә ашырган муниципаль районда, шәһәр округында (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге районында) хезмәткә сәләтле яшьтәге халык санына карап, узган ел башына Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы мәгълүматлары нигезендә билгеләнә.»;

5 нче таблицаның «Күләм күрсәткеченең әһәмияте (аерым муниципаль берәмлекнең, шәһәр округының хезмәт ресурслары саны), мең кеше» графасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Территориясендә Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган күләмле күрсәткечнең әһәмияте (муниципаль районда, шәһәр округында (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге районында) хезмәткә сәләтле яшьтәге халык саны), мең кеше».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин